| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

ПРИКАЗ БОЕРЫК

__30.09.2022_______ Казан шәһәре № ___111____

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 15 февралендәге 12 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 15 февралендәге 12 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 21 февралендәге 19 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның «а» пунктчасында:

«дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар» сүзләренә алмаштырырга;

«Хокук идарәсе» сүзләрен «Өлешле төзелешне контрольдә тоту һәм хокукый эш идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның «б» пунктчасының беренче абзацында «дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәтенең кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта «дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча»

сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.2 пунктта «кызыксынган оешмалар» сүзләреннән соң «, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасы кулланылырга мөмкин, шул исәптән гаризалар юллау өчен дә» сүзләрен өстәргә;

3.5 пунктның «б» пунктчасында «дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар» сүзләренә алмаштырырга;

3.31 пунктта «дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенең хокук бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ һәм мәгълүмат технологияләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче В.А. Кудряшов